ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

15 декабрь, 2017 ел № 21/8

Шәһәр Советының 2015 елның 22 октябрендәге «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2/11 санлы Карарына үзгәрешләр кертү хакында

2017 елның 30 сентябрендәге «Россия Федерациясе Салым кодексының икенче өлешенә һәм Россия Федерациясенең аерым законнарына үзгәрешләр кертү турында» 286-ФЗ санлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставының 28 маддәсе нигезендә

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Шәһәр Советының 2015 елның 22 октябрендәге «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2/11 санлы Карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) 2 пунктның 3 нче пунктчасында:

– өченче абзацта «йорт» сүзе алдыннан «торак» сүзен өстәргә;

– дүртенче абзацта «бер торак бина (торак йорт)» сүзләрен «бер торак йорт» сүзтезмәсенә алыштырырга»;

2) 4 пунктның тугызынчы абзацын яңа редакциядә бәян итәргә:

«Салымнар һәм җыемнар хакында законнар нигезендә салым ташламасына хокуклы физик затлар салым органына ташлама бирү турында гариза бирәләр, шулай ук салым ташламасына хокукы булуны раслаучы документларны да тапшыра алалар».

3) кушымтаны гамәлдән чыккан дип танырга

2. Әлеге Карар 2018 елның 01 гыйнварыннан үз көченә керә..

3. Әлеге Карар үтәлешен тикшереп торуны Шәһәр Советының социаль-икътисадый үсеш мәсьәләләре һәм бюджет буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев

ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ РЕСПУБЛИКИ ... ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ ...
ПРОТОКОЛЬНАЯ ЧАСТЬ
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ